| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 5 июне №21

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүченең - физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы (картлар, инвалидлар, яшь инвалидлар, инвалид балалар, сугыш һәм хезмәт ветераннары; интернат-йортларда, шул исәптән психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар йортларында; махсус интернат-йортларда, шул исәптән картлар һәм башкалар өчен) җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә;

3) ата-анасы ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче балигъ булмаган физик затлар;

4) җирле үзидарә органнары документларын раслаган очракта, аз керемле физик затлар;

5) суд карары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә суд тәртибендә хокукка сәләтсез дип танылган психик тайпылышлар булган физик затлар;

6) иректән мәхрүм итү урыннарындагы физик затлар - иректән мәхрүм итү урыннарында булу чорына суд карары нигезендә;

7) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

8) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач;

9) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3, 4 өлеше һәм 47 пункты нигезендә башкарма производствоны түләтүчене кире кайтару турында суд приставы-башкарма карар чыгарганда;

10) өч елдан артык бурыч барлыкка килү датасы белән түләтү мөмкинлеге булмау турында акт булганда;

11) 2006 елның 1 гыйнварына кадәр бурыч недоимкасы булганда;

12) ЕГРЮЛда мәгълүмат булмаган юридик затлар;

13) недоимкага исәпләнгән пеналар буенча бурыч булган юридик затлар, аны түләтү срогы тәмамланганнан соң, алар исәпләгән недоимка булмаган очракта.

2.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар буенча недоимканы, бу салымнар буенча пеналар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2014 елның 09 июлендәге 16 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга (06.07.2017 №15, 19.09.2022 №19, 19.12.2022 № 30 үзгәрешләр белән)

3.Әлеге карарны Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урам, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында -Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урам, 23 йорт буенча, ФАП бинасында-Мельничная урамы, 23 йорт , Югары Чыршылы авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылында Совет урамы 13 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Советы рәисе Н.Я. Хәйруллина